КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1249

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 24 февраль, 92 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «рәвешендә грант» сүзләрен төшереп калдырырга, «затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга» сүзләрен «затларга эшкә урнашуда һәм эшкә урнашкан чорда даими ярдәм итеп торуда булышлык күрсәтүне» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда

ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибенең һәм шартларының 4.3 пунктындагы «д» пунктчасында «рәвешендә грант» сүзләрен төшереп калдырырга, «затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга» сүзләрен «затларга эшкә урнашуда һәм эшкә урнашкан чорда даими ярдәм итеп торуда булышлык күрсәтүне» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмаларның аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүгә һәм алар эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин